УДК 297.908

***А.М. Сәлахов***

# МӨХӘММӘТШАКИР БУАВИНЫҢ «ШӘРАИТЕЛ-ИМАН» АҢЛАТМАСЫНДА ТӘФСИР КИТАПЛАРЫННАН КУЛЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР

Данная статья посвящена краткому описанию тафсиров, которые использовал Мухаммад-Шакир Буави (имам Бурнаевской мечети г. Казани в конце XIX – в начале XX в.) в своем комментарии к популярному среди мусульман-татар тексту «Шара’ит аль-иман» (Условия веры). В статье также приводятся некоторые биографические сведения об авторах рассмотренных работ.

В сочинении Буави имеются фрагменты толкований на Коран следующих авторов: «Мафатих аль-гайб» (Ключи к сокровенному) Фахр ад-дина ар-Рази, «Анвар ат-танзиль ва асрар ат-та’виль» (Светочи откровения и тайны истолкования) Насыр ад-дина аль-Байдави, «Мадарик ат-танзиль ва асрар ат-та’виль» (Постижение откровения и тайны истолкования) ‘Абдаллаха ан-Насафи, «Тафсир аль-Джалялейн» (Тафсир двух Джалалов) Джаляль ад-дина аль-Махалли и Джаляль ад-дина ас-Суйюты, «Рух аль-баян» (Дух разъяснения) Исма‘иля Хаккый, «Мавахиб ‘алиййя» (Высокие дары) Хусайна аль-Кашифи.

Наличие в работе Буави цитат из тафсиров, составленных авторитетными мусульманскими учеными, свидетельствует о высокой степени образованности автора и научном характере его сочинения.

**Ключевые слова:** имам Бурнаевской мечети, комментарий к «Шара’ит аль-иман» (Условия веры), тафсиры, биографические сведения

This article is dedicated to a brief description of the tafsirs used by Muhammad Shakir Buavi (Imam of the Burnaevskaya Mosque in Kazan in the late 19th and early 20th centuries) in his commentary on the text “Shara’it al-iman” (Conditions of Faith), popular among Tatar Muslims. In Buawi’s work there are fragments of commentaries on the Quran by the following authors: “Mafatih al-ghayb” (Keys to the hidden) by Fakhr ad-Din ar Razi, “Anwar at-tanzil wa asrar at-ta’wil” (Lamps of revelation and the secrets of interpretation) by Nasir ad-din al-Baydawi, “Madarik at-tanzil wa asrar at-ta’wil” (Comprehension of revelation and the mystery of interpretation) by Abdullah an Nasafi, “Tafsir al-Jalalayn” (Tafsir of two Jalals) by Jalal ad-din al-Mahally and Jalal ad-din al-Suituty, “Rukh al-bayan” (The Spirit of Clarification) by Ismail Hakkiy, “Mawahib ‘aliyyah” (The Highest Gifts) by Husayn al-Kashifi. The presence in Buavi’s work of quotations from tafsirs compiled by authoritative Muslim scholars testifies to the high level of education of the author and the scientific nature of his work.

**Keywords:** Imam of the Burnaevskaya Mosque, commentary on “Shara’it al iman” (Conditions of Faith), tafsirs, biographical information

2024–2025 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә (Мирасханә) игътибарыбызны Мөхәммәтшакир бине Габделҗәббар Буави тарафыннан

төзелгән «Шәраител-иман» (Иман шартлары) текстына язылган аңлатма җәлеп итте [1].

Мөхәммәтшакир Буави турында Р. Фәхреддиннең (1859–1936) «Асар» исемле библиографик җыентыгында түбәндәге мәгълүматлар китерелә:

«Казан шәһәрендә өченче җамигъда имам булып, өч йөз утыз тугызынчы (1339/1921) ел, 29 шәүвәлдә (5 июль) вафат булды. Яше 73 тә иде.

Буа шәһәрендә дөньяга килеп, уку яшьләренә җиткәндән соң, Буада Габденнәсыйр бине Әмин, Казан шәһәрендә Гыяседдин бине Хәбибулла, Мәрҗани хозурларында тәхсил итте (*гыйлем алды*). Бохарага сәфәр итеп, дәресләрен хәтем кылды. Бохарадагы остазлары: дамелла Габдешшөкүр[1], дамелла Ихтыяр хан Әгъләм, дамелла әс-Саратаги вә башкалар.

Бу мәмләкәткә кайткандан соң, ошбу мәсҗед хозурында имам булып гомер сөрде. Зәкявәте (*зирәклеге*) камил булмаса да, иҗтиһадлы вә истикамәтле (*намуслы*), моталәгага һәвәсле булуы сәбәбендән, гыйлеменә мәтанәт (*ныклык*) бирде. Тәкъриренә нисбәт берлә каләме көчле иде. Гарәпчә тәртип иткән бәгъзе бер әсәрләре матбугат берлә нәшер дә ителделәр. Рәсме хаты[2] әгъля (*югары*) дәрәҗәдәдер.

Сахибе тәрҗемә (*тәрҗемәи хәл иясе*) хәбәрле вә хәлим һәм дә җумард булып, адаб мәҗлесен ригаять итүче (*кайгыртучы*) вә хәтер ригаять кылучы иде.

Балалары: Мөхәммәдфарук, Габделхаликъ, Габденнур, Мәсгуд, Камилә, Мәсгудәдер. Ошбу тәрҗемәи хәл, үзенең кызы Камилә тарафыннан тәртип ителгән әсәрдән ихтисар кылынып (*кыскартылып*), бу урынга куелды» [11].

Мөхәммәтшакир Буави әсәренең тарихи һәм фәнни әһәмияте аның татарлар яшәгән җирләрдә генә түгел, ә гомумән хәнәфи мәзһәбендәге төрки халыклар арасында кулланылган мәшһүр чыганаклар нигезендә язылганлыгы да күрсәтә.

Әлеге мәкаләдә без авторның үз хезмәтендә кулланылган тәфсир китаплары һәм аларның төзүчеләре хакында берникадәр мәгълүмат бирербез.

*Тәфсир* сүзенең төп лексик мәгънәсе − «аңлату», «бәян итү» [6]. Фән исеме буларак «Тәфсир – Аллаһтан Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның салаваты һәм сәламе булсын) иңгән китапны аңлата, аның мәгънәләрен бәян итә, аның хөкемнәрен һәм хикмәтләрен чыгара торган гыйлем» дип билгеләнә [2].

Изге Коръән иңгән дәвердә Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның салаваты һәм сәламе булсын) аның мәгънәләрен сахабәләренә үзе аңлатып барган. Соңрак бу вазифа сахабәләргә һәм алардан соң килгән буынга күчә. Бу төр тәфсиргә *тәфсир нәкъли*, ягъни *риваять-*

---

[1] Дөресе: «Габдешшәкүр».

[2] Дөресе: «хатты».

*кә нигезләнгән тәфсир* исеме бирелә. Аннан соң мөселманнарда төрле фәннәр (грамматика, стилистика, ислам хокукы (фикъһ), догматика (кәлям) һ. б.) барлыкка килү нәтиҗәсендә Коръән Кәрим мәгънәләре шул белемнәр яссылыгында аңлатыла башлый. Әлеге төр тәфсир *тәфсир гакли*, ягъни *рационалистик тәфсир* дип атала [3: 132].

Мөхәммәтшакир Буави үзенең хезмәтендә түбәндәге галимнәрнең тәфсирләреннән файдалана: Фәхреддин әр-Разинең «Мәфатихел-гайб» (Яшерен булганга ачкычлар), Насыйреддин әл-Бәйдавинең «Әнварет-тәнзил вә әсрарет-тәэвил» (Иңгән [китап] нурлары һәм аңлату серләре), Габдулла ән-Нәсәфинең «Мәдарикет-тәнзил вә әсрарет-тәэвил» (Иңгән [китапның мәгънәләренә] төшенү һәм аңлату серләре), «Тәфсирел-Җәлаләйн» (Ике Җәлал тәфсире), Исмәгыйль Хәкъкыйның «Рухел-бәян» (Бәян итүнең рухы), Хөсәен әл-Кәшифинең «Мәваһиб галия» (Югары бүләкләр) әсәрләреннән.

## Фәхреддин әр-Разинең «Мәфатихел-гайб» тәфсире

Фәхреддин Мөхәммәд бине Гомәр әр-Рази (1149–1210) − күренекле галим, төрле фәннәрдән, аеруча ислам теологиясе (гыйльмелкәлям), буенча күпсанлы хезмәтләр авторы. Тәэсирле вәгазьләр белән танылган өчен үзенә әл-Хатыйб кушаматы бирелә [10].

Әр-Рази тәфсире берничә өлештән тора. Аның Казандагы Россия ислам институты китапханәсендә сакланган нөсхәсе 11 томнан гыйбарәт.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, әр-Рази тәфсиренең үзе язган өлеше Коръән текстының яртысыннан бераз гына арткан («Пәйгамбәрләр» сүрәсенә җиткән). Тәфсирнең калган өлеше исә башка галимнәр (Шиһабеддин әл-Хуви һәм Нәҗмеддин әл-Камули) тарафыннан башкарылган дип фаразлана. Әлеге тәфсирне төзүдә берничә кеше катнашуга карамастан, ул бер генә өслүбтә язылган. Әр-Рази тәфсиренең галимнәр арасында киң таралганлыгы анда төрле фәннәргә кагылышлы мәгълүматларның күп булуы белән аңлатыла.

Әр-Рази еш кына Коръәндә математика, табигать фәннәре, астрономия һәм башка гыйлемнәр чагылган мәсьәләләр буенча фикер йөртә. Моннан тыш ул күп очракларда философлар карашларының дөрес түгеллеген исбат итә. Шәригать хөкемнәренә кагылышлы аятьләрне аңлатып барганда, төрле галимнәрнең карашларын искә алганнан соң, әр-Рази үзе тоткан (әш-Шәфигый) мәзһәбкә караган дәлилләргә нигезләнә, шуңа өстенлек бирә.

Әр-Рази шулай ук фикъһ нигезләре (мөселман хокукы методологиясе), гарәп теле грамматикасы, стилистика фәннәренә кагылышлы мәсьәләләргә дә игътибар юнәлтә.

Әлеге тәфсирнең тагын бер үзенчәлеге − янәшә килгән аять һәм сүрәләрнең мәгънә ягыннан бәйләнешләренең аңлатылуы.

Гомумән, әр-Рази әсәре тәфсир буларак кына түгел, бәлки теология, космология һәм табигать фәннәре буенча энциклопедик хезмәт дип тә каралырга хаклы [3: 249–253].

### Насыйреддин әл-Бәйдавинең «Әнварет-тәнзил вә әсрарет-тәэвил» тәфсире

Насыйреддин Габдулла бине Гомәр әл-Бәйдави (1286 да вафат) – төрле фәннәрдән күпсанлы хезмәтләр авторы; Ирандагы Шираз шәһәренең баш казые. Фикъһ нигезләре белеме буенча «Минһаҗел-вөсул иләэ гыйльмел-ысул» ([Фикъһ] нигезләре белеменә ирешү юлы) һәм мөселман фәлсәфәсенә багышланган «Тәвалигыль-әнвар» (Беренче нурлар) китапларының авторы буларак дан казанган [8: 97–98].

Әл-Бәйдави тәфсире урта күләмдәге тәфсир булып санала; дүрт томнан тора. Автор үзенең аңлатмалары белән бергә, сүзләрнең ясалышларын аңлатканда, әр-Рагыйб әл-Әсфәхани тәфсирен куллана, синтаксис һәм стилистикага кагылышлы урыннарда әз-Зәмәхшаринең «әл-Кәшшаф» тәфсиреннән өземтәләр күреп була. Космология белән бәйле аятьләр эчтәлеген ачканда, әл-Бәйдави, әр-Рази кебек, табигать күренешләре һәм галәм төзелеше турында фикер йөртә. Догматика (иман) мәсьәләләренә кагылышлы аятьләр сөнни мөселманнарының гакыйдәсеннән чыгып бәян ителә һәм аның дөреслеге исбатлана. Үз эченә фикъһ мәсьәләләрен алган аятьләрне тәфсирләп барганда, авторның үз (әш-Шәфигый) мәзһәбенең дөреслеген дәлилләгән очраклар да бар. Кайбер урыннарда сахабәләрдән китерелгән риваятьләр аятьләрнең мәгънәләрен тагы да ачыклап килә.

Әл-Бәйдави тәфсиренә шәрехләр күп язылу аның фәнни кыйммәтен дә күрсәтеп тора. Тәфсир тирән мәгънәле, киң һәм сыемлы тәгъбирләр белән язылганга күрә, аның эчтәлеген аңлау өчен укучыдан махсус әзерлек сорала [3: 254–259].

### Габдулла ән-Нәсәфинең «Мәдарикет-тәнзил» тәфсире

Әбел-Бәракәт Габдулла бине Әхмәт ән-Нәсәфи (1310 да вафат) – Мөселман хокукы, хәдис, тәфсир, кәлям белемнәре галиме. Күпсанлы хезмәтләр авторы; шулар арасында гыйльмел-кәлямнән «Гомдәтел-гәкаид» (Ышанырга тиеш булган әйберләрнең нигезе) һәм аңа «Игътимад» (Терәк) исемле аңлатма, фикъһ нигезләре буенча «Мәнарел-әнвар» (Нурлар маягы), фикъһ буенча «әл-Кафи фи шәрхел-вафи» (әл-Вафи [китабына] җитә торган шәрех), «Кәнзед-дәкаик» (Нюанслар хәзинәсе) [8: 32].

Әлеге тәфсир әл-Бәйдави белән әз-Зәмәхшари тәфсирләренә нигезләнеп язылган. Стилистикага кагылышлы «әл-Кәшшаф»тан алынган аңлатмалар ән-Нәсәфи аңлатмалары эчендә үзгәртелеп бирелсә, әл-Бәйдави тәфсиреннән өземтәләр исә кайбер очракларда үзгәртелмичә яки беркадәр үзгәртүләр белән генә китерелә. Фикъһка кагылышлы аятьләргә тәфсирдә автор төрле галимнәрнең карашларын әйтеп китә һәм күп очракларда үзе тоткан (хәнәфи) мәзһәбнең дөреслеген дәлилли. Тәфсир җиңел һәм аңлаешлы өслүбтә язылганлыгы белән аерылып тора [3: 260–264].

### «Тәфсирел-Җәлаләйн»

«Тәфсирел-Җәлаләйн», ягъни ике Җәлаледдин тарафыннан язылган тәфсир.

Җәлаледдин Мөхәммәд бине Әхмәт әл-Мәхәлли (1389–1459). Тәфсир, фикъһ, фикъһ нигезләре, кәлям, мантыйк фәннәре галиме. Күпсанлы хезмәтләр авторы; шулардан фикъһ буенча (әш-Шәфигый мәзһәбе) әш-Ширази язган «әт-Тәнбиһ» китабының кыскартмасы − «Мохтәсар әт-тәнбиһ», фикъһ нигезләре буенча әс-Сөбкинең «Җәмгыль-җәвамигъ» китабына аңлатма, грамматика буенча Ибне Малик төзегән «Тәсһилел-фәваид вә тәкмилел-мәкасыйд» китабына аңлатма һ. б. [9]. Каһирәдәге мәшһүр әл-Мөэйәдия һәм әл-Бәркукыя мәдрәсәләрендә мөгаллимлек иткән.

Җәлаледдин Габдрахман бине Әбел-Бәкер әс-Сөюти (1445–1005) Каһирә шәһәрендә туа. Әш-Шәфигый мәзһәбе вәкиле; төрле фәннәр белгече. Үз чорында хәдис өлкәсендә иң зур галим булып саналган; 200 000 хәдисне яттан белгән, мөгаллимлек эшен алып барган. Күпсанлы мәшһүр хезмәтләр авторы: «әд-Дөрр әл-мәнсур фит-тәфсир бил-мәэсүр» тәфсире, лексикология буенча «әл-Мөзһир фил-люга», хәдис буенча «әл-Җамигъ әс-сәгыйрь» хезмәтләре һ. б. [7].

Бу тәфсирнең «Мәгарә» сүрәсеннән башлап «Кешеләр» сүрәсенә хәтле өлешен һәм «Фатиха» сүрәсенең тәфсирен Җәлаледдин әл-Мәхәлли яза. Ләкин тулысынча башкарып чыга алмый, вафат була. Тәфсирнең калган өлешен, ягъни «Сыер» сүрәсеннән алып «Исра» сүрәсенә хәтле, аның укучысы Җәлаледдин әс-Сөюти башкара.

Тәфсир аңлаешлы телдә, җыйнак җөмләләр белән язылган. Кайбер аятьләрнең мәгънәләрен төгәлрәк аңлату өчен, аларның сүзгыйбарәләренә синтаксик анализ да ясала. Күләме зур булмаса да, әлеге тәфсир – мөселман дөньясында иң киң таралган тәфсирләрнең берсе. Аңа күпсанлы шәрехләр язылган. Аларның иң популяр, таралганнарыннан Мисыр галимнәре Сөләйман бине Гомәр әл-Гаҗилинең (1790 да вафат) «әл-Фөтухат әл-илаһия» һәм Әхмәт бине Мөхәммәд әс-Савинең (1761–1825) «Хашиятес-Сави» тәфсирләре санала [3: 285–288].

### Исмәгыйль Хәкъкыйның «Рухел-бәян» тәфсире

Исмәгыйль Хәкъкый бине Мостафа әл-Хәлвәти (1715 тә вафат) төрек нәселеннән. Истанбул, Бурса шәһәрләрендә яши, әл-Хәлвәтия суфи тарикате әгъзасы булып тора. Төрле фәннәр буенча гарәп һәм төрки телләрдә күпсанлы хезмәтләр яза. Суфичылык буенча – «әр-Рисалә әл-Халилия», хәдис буенча – «Әрбәгунә хәдисән», грамматика буенча «әл-Фөрукат» әсәрләре һ. б. [5].

Тикшеренүчеләр билгеләгәнчә, Хәкъкый үзенең тәфсирен төрле фәннәр буенча язылган китапларга нигезләнеп төзегән. Тәфсир фәненнән кулланылган иң әһәмиятле чыганаклардан түбәндәгеләрне санап китәргә мөмкин: әс-Сәмәркандинең «Бәхрелголум» (Гыйлемнәр диңгезе), әл-Баһавинең «Мәгалимет-тәнзил»,

әз-Зәмәхшаринең «әл-Кәшшаф», әр-Разинең «Мәфатихел-гайб», «Тәфсирел-Җәлаләйн» һ. б. Әбүс-Сөгуднең «Иршадел-гаклес-сәлим» (Сәламәт гакыл өчен туры юл) тәфсире аеруча зур йогынты көченә ия була.

Тәфсирләрдән тыш, Хәкъкый Коръән белемнәре (голумел-Коръән), хәдис җыентыклары, суфичылык, фикъһ, фикъһ нигезләре, гакыйдә, тәрҗемәи хәлләр тупланмасы, лексикология һәм лексикография буенча хезмәтләрне дә файдаланган. Хәкъкый, гадәттә, аңлатмаларның бер варианты белән генә чикләнә, кирәк булган очракларда синтаксик анализ да ясый, якынча һәрбер сүзнең мәгънәсен аерым ачыклый, еш кына аятьләрнең иңү сәбәпләрен дә әйтеп китә. Вәгазь-хикәяләр, риваятьләр тәфсирдә аерым урын алып тора. Кайбер очракларда аятьләр арасындагы бәйләнеш тә аңлатыла. Фикъһка кагылышлы аятьләрне Хәкъкый үзе тоткан хәнәфи мәзһәбе яктылыгында аңлата [4].

### Хөсәен әл-Кәшифинең «Мәваһиб галия» тәфсире

Хөсәен бине Гали әл-Кәшифи (910 да вафат) – фарсы нәселеннән. Ирандагы Сәбзәвар шәһәрендә туа, соңра Һерат шәһәренә күчә. Суфи, шагыйрь, төрле фәннәр, аеруча хәдис һәм тәфсир белгече. Фарсы телендә язылган күпсанлы хезмәтләр авторы: тарих буенча – «Рауза-теш-шөһәда» (Шәһитләр бакчасы), «әр-Рисалә әл-галия фил-әхадис эн-нәбәвия» (Пәйгамбәр хәдисләренә кагылышлы бөек рисалә) хәдисе, «Бәдаигыль-әфкяр фи сәнаигыль-әшгарь» (Шигырьләрне иҗат итү белән бәйле гаҗәеп уйлар) исемле шигырьләр җыентыгы, «Җәваһирет-тәфсир» (Тәфсир җәүһәрләре). Вәгазьләр сөйләү белән шөгыльләнә [13].

Әл-Кәшифи тәфсире җиңел һәм аңлаешлы тел белән язылган. Әлеге тәфсирдә Коръән аятьләрендә булган сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең кыскача мәгънәләре аңлатыла. Кайбер урыннарда аңлатыла торган аятьләргә мөнәсәбәтле шигырьләр, гыйбрәтле кыйссалар һәм хикәяләр китерелә. Тәфсирдә Аллаһы Тәгаләне таныту, укучыга рухи һәм әхлакый тәрбия бирү максат итеп куела [12].

Югарыда язылганнарга нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Буавиның хезмәтендә абруйлы мөселман галимнәре хезмәтләрен файдалануы аның укымышлы, зур белемгә ия булганын да, аңлатмаларының фәнни нигезле, дәлилле икәнен дә күрсәтеп тора.

### Әдәбият

1. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 39 ф., 419 сакл. бер.

2. *Әз-Зәркәши Б.* Әл-Борһан фи голумел-Коръән. Бәйрут: Дарел-мәгърифә. Т. 1. Б. 13.

3. *Әз-Зәһәби М.Х.* Әт-Тәфсир вәл-мөфәссирун. Каһирә: Дарел-хәдис. Т. 1. 416 б.

4. *Әз-Зәһәби М.Х.* Әт-Тәфсир вәл-мөфәссирун. Каһирә: Дарел-хәдис. Т. 3. Б. 379–382.

5. *Әз-Зирикли Х.* Әл-Әгълям. Бәйрут: Дарел-гыйлем лил-мәләйин, 1986. Т. 1. Б. 313.

6. *Ибне-Мәнзур*. Лисанел-гарәб. Бәйрут: Мөэссәсә әт-турас әл-гарәби, 1993. Т. 10. Б. 261.

7. *Кәххаля Г.Р.* Мөгъҗәмел-мөъәллифин. Бәйрут: Дар Ихъяъэ әт-турас әл-гәраби. Т. 5. Б. 128.

8. *Кәххаля Г.Р.* Мөгъҗәмел-мөъәллифин. Бәйрут: Дар Ихъяъэ әт-турас әл-гарәби. Т. 6. 295 б.

9. *Кәххаля Г.Р.* Мөгъҗәмел-мөъәллифин. Бәйрут: Дар Ихъяъэ әт-турас әл-гарәби. Т. 8. Б. 311–312.

10. *Кәххаля Г.Р.* Мөгъҗәмел-мөъәллифин. Бәйрут: Дар Ихъяъэ әт-турас әл-гарәби. Т. 11. Б. 79.

11. *Фәхретдин Р*. Асар. Казан: Рухият, 2006. 3 т. Б. 353–354.

12. URL: https://www.aqlamalhind.com/?p=1934

13. URL: https://ketabonline.com/ar/books/96978/read?part=1&page=87&index=5329062/5329066

***Сәлахов Габдулла Мөнир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Салахов Абдулла Мунирович,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искуства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*abdullasalakhov@yandex.ru*